СОВЕТ
СЕЛО-УБЕЙСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Улица Мира, дом 40, село Новый Убей,
Дрожжановский район 422464

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УБИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Тынычлык урамы, 40 нче йорт, Яна Уби авылы,
Чүпрәле районы 422464

Тел.: (84375) 3-55-35, 3-55-36, e-mail: Subey.Drz@tatar.ru,
www. subey -drogganoe.tatarstan.ru

---

Яна Уби авылы

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

24 сентября 2024г. № 48/1

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уби авыл җирлеге Советының 11.11.2019 елның № 62/2 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2024 елның 12 июлендәге 176-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уби авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Чүпрәле муниципаль районы Уби авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 11.11.2019 №62/2 карарына (21.05.2020 №74/2, 15.11.2022 №28/2, 09.10.2023 №38/1 редакциясендә), **2 пунктның 4 пунктчасына** түбәндәге эчтәлекле абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

«- РФ Салым кодексының 378.2 маддәсе 7 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы күрсәтмәсе белән раслана торган исемлеккә кертелгән гомуми мәйданы 1 000 квадрат метрдан артыграк булган административ-эшлекле үзәкләргә һәм сәүдә үзәкләренә (комплексларына) карата 1,2%;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Уби авыл җирлеге Уставы нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Уби җирлеге башлыгы: А.П. Ярухин